СОВЕТ МУЛЬМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422731, Республика Татарстан, Высокогорский район
с. Мульма, ул. Центральная, 46а

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МҮЛМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422731, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Мүлмә авылы, Үзәк ур, 46а

Тел./факс: +7(84365) 70-2-03, e-mail: Mulm.Vsg@tatar.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**11 сентябрь 2020 ел.** **№ 216**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы «Мүлмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәсенә үзгәрешләр кертү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 14.1 статьясындагы 1 өлеше, 2004 елның 28 июнендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Мүлмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Мүлмә авыл җирлеге Советының 2019 елның 27 нче июнендәге 158 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы «Мүлмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәсен раслау турындагы» карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Мүлмә авыл җирлеге Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәсенең 3.3 пунктына түбәндәге эчтәлектәге 16 пункт белән тулыландырып үзгәрешләр кертергә:

«16) полиция участок уполномоченные вазыйфасын биләүче хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәр тарафыннан күрсәтелгән вазыйфаны биләгән чорга торак урыны бирү.».

2. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталының рәсми сайтында: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе урынбасары,
Авыл җирлеге Башлыгы урынбасары Л.Р. Зиннәтүллин